وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلا تَفَرَّقُواْ

Ий мөәминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

Дин вә Мәгыйшәт

№12 (109). 4 ноябрь 2011 / 8-зөлхиҗҗә-1432

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Әлмәттә кунакта ▷2◁

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ: "Халкыбызны ислам дине саклап калды" ▷3◁

Изгелек җирдә ятмас... ▷4◁

КОРБАН БӘЙРӘМЕ МӨБАРӘК БУЛСЫН!

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.МИҢНЕХАНОВның Корбан-бәйрәме уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

2011 елның 6 ноябре

Хөрмәтле Татарстан мөселманнары! Сезне чын йөрәктән изге Корбан-бәйрәме белән тәбрик итәм!

Бу бәйрәмнең тантаналы мизгелләрендә без иманыбыз ныгуга, яңа рухи тәҗрибә алуыбызга, эчке гармониягә ирешүебезгә сөенәбез. Әлеге бәхетле көннәрдә мәчеттә моңлы азан яңгырый, барлык мөәмин-мөселман догаларын Аллаһы Тәгаләгә юллый. Коръәни-Кәримдә әйтелгәнчә: "Сәдака - авырлыкларны җиңү юлы". Мохтаҗларга ярдәм күрсәтеп һәм игелек кылып һәрберебез аларның хәленә керә, күңелләренә бәхет индерә, йөрәкләренә шәфкать һәм мәрхәмәт орлыклары сала.

Татарстандагы күркәм дини традицияләр милли үзенчәлекләрне, халкыбызның күп гасырлык бай мирасын саклауга, җәмгыятьнең әхлакый нигезләрен һәм дин тотучыларның бердәмлеген ныгытуга ярдәм итә. Республикабыз мөселманнары, Татарстандагы традицион дин вәкилләре белән дус-тату яшәп, җәмгыятьнең рухи яңарышында һәм үзара аңлашу процессында алга таба да актив роль уйнар, дип ышанам.

Корбан бәйрәме барыбызга да көч һәм илһам өстәсен, игелекле гамәлләргә рухландырсын, һәр йортка, һәр гаиләгә шатлык һәм өмет китерсен!

Сезгә җан тынычлыгы, сәламәтлек, муллык һәм иминлек телим!

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н.МИҢНЕХАНОВ

Корбан гаете уңаеннан Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле татарстанлылар!

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән барлык дин кардәшләребезне дә иң олы һәм мөбарәк бәйрәмнәрнең берсе булган Корбан гаете белән котлыйм.

Корбан гаете, ислам динендәге башка бәйрәмнәр кебек үк, күркәм эшләр кылуны, рухи чисталыкка ирешүне һәм гөнаһларыбызны ярлыкауны гәүдәләндерә.

Әлеге бәйрәм бигрәк тә авыруларга, бәла-казаларга юлыккан мөселман кардәшләребезгә, олы буын вәкилләренә, ятимнәр һәм мохтаҗларга битараф калмаска, аларга игътибар илә ихтирам күрсәтергә чакыра. Тормышта, матди байлыктан бигрәк, якыннарыңның, туганнарыңның игътибары һәм җылы мөгамәләсе күпкә кыйммәтрәк булуын искәртә.

Корбан чалу - кешеләр өчен Аллаһ тарафыннан билгеләнгән, пәйгамбәрләр кылган вә безгә кушып калдырылган изге гыйбадәтләрнең берсе. Әлеге бәйрәм көннәрендә Аллаһы Тәгаләгәнең бөеклегенә, Исламның хак дин булуына тагын бер кат инанабыз. Мөселманнар, Ибраһим галәйһиссәламнең юлын дәвам итеп, рухи-әхлакый камиллеккә, бер-берсенә хәерхаһлы булуга ирешә.

Әлеге бәйрәмнең республикабыздагы халыкара дуслыкны, бердәм хезмәттәшлекне ныгытуга, мөселман өммәтен берләштерү өчен ярдәм итәсенә чын күңелдән ышанам.

Ихластан татарстанлыларны Корбан гаете белән тәбрик итәм. Аллаһы Сөбхәнәһү вә Тәгалә һәрбарчабызга да күңел тынычлыгы, иман байлыгы, бәрәкәтле озын гомерләр насыйп әйләсә иде. Кылган догаларыбызны, изгелекләребезне, биргән садакаларыбызны һәм дә инде чалган корбаннарыбызны кабуллардан кылып, калебләребезне бәйләп, мөселман өммәтен берләштерсә иде.

Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ

Татарстанның баш казые: "Егерме меңнән сум акчасы булган кешегә корбан чалу мәҗбүри"

- 31 октябрь көнне Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Президиумы утырышында гаеткә әзерлек мәсьәләләре каралды, - дип башлады үз сүзен Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ.

Корбан гаете көнне, ягъни 6 нчы ноябрьдә кояш мәркәзебез Казанда сигез туларга бер минут кала чыга. Быелдан башлап сәгать телләрен бүтән "кышкы вакыт"ка күчермәячәкбез, өйлә, җомга вакытлары да ел әйләнәсе 13.02 сәгатьтә калачак. Тик кайбер календарьларда октябрьнең соңгы якшәмбесеннән башлап намаз вакытлары "кышкы вакыт"та бирелгән. Әлеге момент аңлашылмаучанлыклар китереп чыгарырга мөмкин, шуңа күрә игътибарлы булырга кирәк.

- Гает намазы - вәҗеб, иртәнге намаз - фарыз. Шуңа күрә без халыкны иртәнге намазга да мәчеткә җыю яклы. Аны җәмәгать белән уку - ялгыз гына укуга караганда егерме җиде мәртәбә саваплырак та бит әле. Шунлыктан халыкны сәгать җидегә җыеп, иртәнге намаз укыячакбыз. Намаздан соң әрвахларга дога кылырга, сигезенче яртыларда Корбан бәйрәме вәгазен башларга, сигез тулып утыз минуттан да соңга калмыйча гает намазын укырга, дигән карарга килдек. Гает - кояш чыгып 20-30 минут узгач, ягъни кояш җирдән ике метр чамасы (сөңге буе) күтәрелгәч укылырга тиеш. Шулай итеп, Татарстанда быел гает намазы вакыты, уртача алганда, сигез тулып утыз минутка туры килә, - диде Ж.Фазлыев.

Мәчеткә бара алмаган кеше корбанын бернинди шик-шөбһәсез сәгать тугыз тулгач чала ала. 6 нчы ноябрьдә вакыты яисә мөмкинлеге булмаганнар әлеге гамәлне 8 нче ноябрьгә кадәр, ягъни сишәмбе көнне кояш баеганчы үтәсә дә дөрес булыр.

ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәиз гает намазын Казандагы "Мәржани" мәчетендә укытыр, дип көтелә. Биредә бәйрәм вәгазе сәгазь тугызда башлана, ул "Татарстан - Яңа гасыр" телеканалыннан турыдан-туры трансляцияләнәчәк. Корбан гаете вәгазен, Аллаһ теләсә, зәңгәр экраннар аша авырып мәчеткә бара алмаучылар, гарип-горабәләр, хатын-кызлар гына түгел, республикабыз мәчетләреннән гает укып кайткан бар халык та карый алачак.

5 нче ноябрь - Гарәфә көне. Шул көннең иртәнге намазыннан башлап (9 нчы ноябрьнең икенде намазын да кертеп), барлыгы - 23 намазда фарызларыннан соң ике якка сәлам биргәннән соң, тәшрик тәкбирен әйтү вәҗеб булачак. Әлеге гамәл фарыз намазларны ялгыз гына кылсаң да, җәмәгать белән укысаң да үтәлергә тиеш.



Гает көнне тагын нинди саваплы гамәлләр үтәргә мөмкин соң? Беренчедән, гает намазына сәхәрдән соң уразадагы кебек ашамыйча-эчмичә бару - бик күркәм эштер. Әйтик, 6 нчы ноябрь көнне кояш якынча сәгать сигезләрдә чыга икән, иртәнге алтыдан соң ризык капмаска кирәк. Гает намазы укып кайткач (беренче корбанның каны җиргә таму белән) ризык кабу бик тә саваплы. Шулай ук корбан шулпасы белән авыз итәргә дә мөмкин.

(Ахары 2 нче биттә.)

Мөхтәсибәт ЯҢАЛЫКЛАРЫ

ЯШЕЛ ҮЗӘН

5 ноябрь көнне Яшел үзән шәһәренең Мирный микрорайонында тантаналы рәвештә мәчет ачылачак. Шәһәргә керү өлешендә урнашкан әлеге ике манаралы мәчетне Корбан бәйрәменә төзеп өлгерттеләр. "Мәчет ачылышына зур-зур кунакларны - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәизне, шәһәр хакимияте вәкилләрен, төрле предприятие җитәкчеләрен чакырдык", - диде Яшел үзән шәһәре һәм Яшел үзән районы имам-мөхтәсибе Габделхәмит хәзрәт Зиннәтуллин.

Элеккеге балалар бакчасы бинасында мәдрәсәбез эшләп килә. Яшел үзән шәһәрендәге әлеге уку йорты үз эшен өч еллык укыту программасы нигезендә алып бара. Бу - башлангыч дини белем бирүче уку йорты. 1998 елда хәрабә хәлендә бирелгән бинаның кайбер өлешләрен төзекләндереп, шул ук елдан үз эшчәнлегебезне алып бара башладык. Мөхтәсибәтебез дә шунда урнашкан. "Таң" исемле газетабыз нәшер ителә. Бүгенге көндә мәдрәсәбездә өч йөз иллеләп кеше укый. Дин гыйлеме алырга теләүчеләр атна уртасында да, шимбә-якшәмбе дә килә, алар биредә яшәп укымый; араларында мәктәп балалары да бар, яшь буенча бернинди чикләүләр куелмаган. Теләкләре генә булсын. Укучылар алга таба белемнәрен югарырак дини уку йортларында дәвам иттерергә теләсә, характеристика һәм юллама бирәчәкбез, ул шәкертнең белем дәрәҗәсен күрсәтү өчен хезмәт итә, - дип аңлатма бирде Г.Зиннәтуллин.

Көзге каникул вакытында балалар өчен лагерь оештырдык. Аларны ашатып-эчертеп, ял вакытларында белем алу өчен шартлар тудырабыз. Лагерь мәдрәсә бинасында уза. "Иртәнге сәгать тугыздан алып 15.00 сәгатькә кадәр балалар лагерьда. Әлеге бер атналык лагерьда балаларга укудан тыш, уеннар да каралган, - диде Габделхәмит хәзрәт. - Лагерьга унбишләп мәктәп баласы килде. Егетләр белән кызлар аерым-аерым төркемнәрдә шөгыльләнә".

Кышкы каникулда да лагерь оештырырга да уйлыйлар. Һәр каникул саен лагерь үткәрү биредә традициягә кергән.

Авылларыбызда тормыш тәҗрибәсен алган, өлкән яшьтәге имамнар хезмәт итә. Олы Ачасыр авылында Габбас хәзрәт имам булудан тыш, остазлык та итә. Ул мәчеттә укуукыту өчен җавап бирә. Аның җитәкчелегендә егерме бишләп бала дәрес ала. Һәр ел саен апрель аенда Коръән уку буенча бәйгеләр үткәрәбез, шул Олы Ачасыр авылыннан әлеге ярышларда шактый бала катнаша.

Мондый бәйге апрельнең соңгы дистәсеннән соң туры килгән пәнҗешәмбегә билгеләнә икән.

P.S.: үткән сентябрьдә Яшел үзән шәһәрендә тагын бер күркәм вакыйга булган. Шәһәрнең корабльләр төзүче Горький заводы территориясендә һәм аның карамагындагы янгын сүндерү частендә тантаналы рәвештә берьюлы ике бина - мәчет һәм православие храмы ачылган.

Әлмәттә кунакта

27 октябрь көнне Голәмәләр шурасы рәисе, Россия ислам университеты-ның уку-укыту эшләре буенча проректоры Рөстәм хәзрәт Батров белән Әлмәт якларына юл тоттык. Әлмәткә беренче генә баруым. Матбугат битләрендә дини сәясәте өчен еш тәнкыйтьләнгән бу шәһәргә барыр алдыннан күңелдә ниндидер хафалану да туган иде. Чыннан да, Әлмәттә вәзгыять катлаулымы, мөхтәсибәтнең яңа идарәсе нинди шартларда эшли икән һ.б.?

Иң беренче эш итеп, Җәмигъ мәчет бинасында урнашкан егетләр мәдрәсәсе шәкертләре белән очраштык. Шәкертләргә Диния нәзарәтенең яшьләр сәясәте, гамәлдәге яшьләр оешмалары һәм яңа оешкан Мөселман яшьләре берлеге турында сөйләдек. Әбү Хәнифә турында китап язган Рөстәм хәзрәт дин әһеленең тормыш юлы, олуг галим нигез салган мәзһәбнең үзенчәлекләре, аның хезмәтләре һәм мирасының төп кыйммәтләре турында сөйләде, шәкертләрне шулай ук Голәмәләр шурасы эшчәнлеге белән дә таныштырды. Килгән кунакларны тыңлаганнан соң шәкертләр Рөстәм хәзрәткә үзләрен кызыксындырган сорауларын яудырды. Аларны бигрәк тә Голәмәләр шурасына сайлану мәсьәләләре кызыксындырды, шәкертләр шулай ук Россия ислам университеты эшчәнлеге, киләчәктә укуларын дәвам иттерүгә бәйле сорауларын да бирде. Биредәге күп кенә студентлар Рөстәм хәзрәт белән "Яңа гасыр" телеканалы ("Актуальный ислам" тапшыруы) аша таныш булган. Гомумән алганда, укучылар үзләрен актив тотты.

Шәкертләр белән очрашудан без бик канәгать калдык һәм үз фикерләребезне мәдрәсә җитәкчесе Энҗе Хәсәншинага җиткердек. Энҗе ханым исә биредәге вәзгыятьнең яхшы якка үзгәрүен һәм уку елы башында мәдрәсәнең эчке тәртип кагыйдәләре белән килешмәгән студентларның үз теләкләре белән китүен әйтте.

Өйлә намазын Җәмигъ мәчеттә укыганнан соң, мәчет картлары белән очраштык. Алар да безгә бирелгән күп кенә сораулары аша Диния нәзарәтенең традицион рухи кыйммәтләре торгызуга, хәнәфи мәзһәбен кайтаруга юнәлтелгән эшчәнлеген хуплаулады. Кайбер мөселман яшьләрендә олы буынга һәм гореф-гадәтләргә карата тиешле хөрмәт булмауга борчылулары турында да фикерләр яңгырады. Күптән түгел генә Казанда узган мөселман кинофестивале турында да сораулар булды, әлеге фестивальнең исеме җисеменә туры килми, дигән нәтиҗә ясалды.

Администрациядә узган кыска вакытлы очрашудан соң, кызлар мәдрәсәсенә юл тоттык. Кызлар сораулар бирү буенча хәтта егетләрне дә уздырды. Аларны күбрәк ижтимагый өлкәгә караган сораулар кызыксындырды. Мисал өчен, яулыклы кызларның эшкә урнашу проблемасы, үз өстеңдә эшләү, сәләтеңне үстерү, мөслимәләрнең ялын оештыру кебек мәсьәләләр... Әлеге сораулар, чыннан да, көн кадагында. Бу өлкәдә эшлисе эшләр күп һәм әлеге проблемаларны чишү өчен кызларның үзләренә дә зур көч куярга туры киләчәк. Рөстәм хәзрәт аларга, РИУдагы кебек, мәдрәсәдә дә дебатлар турниры үткәрергә киңәш итте.

Гомумән, Әлмәткә бару, шәкертләр белән очрашу бездә бары тик уңай фикерләр генә калдырды. Күп эш башкарылган. Ә киләсе адым, минемчә, барлык мөселман уку йортларының уку-укыту программаларын бер калыпка салу булырга тиештер. Болай эшләгәндә, Әлмәт мәдрәсәсе шәкертләре үз белемнәрен РИУ кебек башка вузларның югары курсларында дәвам иттерә алачак.

Без киләчәктә тагын да ныклы элемтәдә торып, бергә-бергә төрле проектлар, акцияләр үткәрү турында да сүз алып бардык. Кыска гына вакыт эчендә район мөхтәсибе Рафикъ хәзрәт Миңнәхмәтов һәм югарыда телгә алынган ике мәдрәсә җитәкчесе Энҗе Хәсәншина ару-талуны белмичә күп эшләр эшләгән. Әлмәттә яңа дини оешма төзеп, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең төп казанышы булган берләшүне, республикабыздагы дини бердәмлекне җимереп, Аллаһы Тәгаләнең: "Һич тә аерылмагыз һәм берберегездән киселеп төрле юлларга китмәгез!" аятенә (Коръәни-Кәримнең "әл-Гыймран" сүрәсендәге 103 нче аять) каршы барудан да курыкмыйча, сәяси уеннарга кереп киткән җитәкчеләрдән аермалы буларак, бу ике кеше ислам өммәтен үстерү, җәмгыятьтә бердәмлек, татулык һәм иминлек урнашсын өчен үз көчләрен жәлләми. Аларга эшләрендә зурдан-зур уңышлар теләп, киләчәктә дә хезмәттәшлек итәрбез, дигән өметтә калам.

Айнур СОЛТАНОВ,
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең яшьләр белән эшләү бүлеге җитәкчесе.

Татарстанның баш казые: "Егерме мең сум акчасы булган кешегә корбан чалу мәҗбүри"

(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)

Гает - ул сөенеч көне, догаларның кабул була торган вакыты. Ә дога кабул булсын өчен без ул көнне Аллаһ риза булырлык итеп үткәрергә тиешбез. Намазларны укыгач, гает сәдакасы бирергә, зиратка барып каберләрне зиярәт кылырга, Коръән укырга киңәш итәбез. Авыру-сырхауларның, туганнарыңның хәлен белү - Аллаһы Тәгалә канәгать була торган гамәлләрдән булыр. Байлыгы көмеш нисабы белән 595 грамм-га җиткән кешегә (быел бу якынча 20 мең сумга туры килә) корбан чалу вәҗеб була. Моңа "тере" акча гына түгел, өеңдә булган барлык "роскошь" - алтын-көмеш эшләнмәләре дә керә. Әҗәте булган кешегә корбан чалу вәҗеб түгел. Әҗәткә кермичә генә корбанлыгын булдыра алган кешегә корбан вәҗеб хөкемендә. Әҗәтенең түләве дә кот очарлык булмаган кеше сарык суеп, аны гаиләсе өчен тота ала. Уйлап кына карыйк: бүгенге көндә әҗәтле кеше дә "әҗәтем бар", дип, ашамыйча-эчмичә тормый бит инде, продукциясен сатып ала. Урта хәлле һәм мохтаҗлыгы булган кеше итне үз гаиләсе өчен кулланса да дөрес була. Итне өчкә бүлү - ул бай кешеләр өчен. Аның берсе - үзе, икенчесе - туганнары, калганы - авыру-сырхаулар өлеше. "Кабатлап әйтәм: кешенең гаиләсе урта хәллеләрдән түбәнрәк икән, корбан итен гаиләсе өчен кулланса да, үзе ашаса да Аллаһы Тәгаләгә якын булыр. Бу гамәлне үтәүченең кальбе чистара. Итне өләшеп бетерергә дигән сүз түгел", - диде Ж.Фазлыев.

"Дога-теләкләребез кабул булсын дисәк, мөмкинлеге булган һәр кешегә корбан чалырга кирәк", - ди Җәлил хәзрәт. Корбан чалмый икән, нинди генә теләк теләсә дә, аның кабул булуы шикле. Чөнки ул вәҗеб гамәлне үтәмәгән була. Шуңа күрә бәйрәм көннәрендә хәер сәдакалары бирергә, туганнарыңның хәлен белергә, ятимнәргә барырга, аларны сөендерергә кирәк.

- Зур бәйрәм табыны әзерләсәк хәерле булыр. Әлбәттә, Яңа елны, туган көннәрне дә хәмерсез табыннар әзерләп үткәрергә ярый. Ә безнең гает табыны ул бөтен табыннардан да матуррак булырга тиеш, чөнки бу бәйрәм барлык дөньяви бәйрәмнәрдән дә өстенрәк бит. Бу көннәрдә без бер-беребезгә бүләкләр бирешергә, хәлләребезне белешергә, котларга тиешбез. Менә бу әлегә халыкта гадәткә кереп бетә алмый, - дип ассызыклады ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең баш казые.

Мөбарәк Корбан бәйрәме көннәрендә тәкәбберлекләребезне ташлап, ата-анабызга, туган-тумачаларыбызга һәм дә барча җан ияләренә ихтирамлы булып, аларның бәхиллекләрен сорап, хәер-догаларын алырга тырышсак иде.

Нияз САБИРҖАНОВ

Сорау – җавап

Сорауларга Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев җавап бирә.

1. Соңгы елларда корбан итен Зөлхиҗҗә аенда ашап бетерергә кирәк, дигән сүзләр йөри башлады. Бу фикер дөресме?

Юк. Радиодан кайбер хәзрәтләр шулай дип чыгыш ясаган иде. Болай дип әйтү өчен бернинди нигез юк. Аны чикләнмәгән срокка кадәр файдаланырга була. Безнең көннәрдә итне саклау өчен суыткычлар бар бит. Күпме сакласаң да, ул корбан ите булудан туктамый.

2. Корбан чалганнан соң ике рәкагать нәфел намазы укырга кирәкме?

Дөрестән дә, корбан чалгач ике рәкагать нәфел яки шөкер намазы уку гадәте бар. Моның бернинди кимчелеге юк. Ул мәҗбүри түгел. Укысак, савабы булыр.

3. Гаеткә барганда тәкбир әйтүнең тәртибе ничек? Ялгыз гына баручы кеше дә тәкбир әйтергә тиешме?

Корбан гаетенә төркем-төркем булып, кычкырып тәкбир әйтеп бару - матур күренеш. Ә Ураза гаетендә бу тәкбир эчтән генә әйтелә. Ялгыз гына барган кеше дә кычкырып тәкбир әйтергә тиеш. Кыскасы, аның тәртибе болайрак. Гаеткә барырга чыккан-нан соң, кушылучылар булмасмы дип, бераз көтеп торырга кирәк. Берәр тыкрыкны узганнан соң, кушылучылар булмасмы дип, янә көтеп торасың. Шул рәвешле, җәмәгатькә кушылып тәкбир әйтелергә тиеш.

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ:

"ХАЛКЫБЫЗНЫ ИСЛАМ ДИНЕ САКЛАП КАЛДЫ"

"ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ" ДОСЬЕСЫ

Тулы исеме: Хатыйп Йосыф улы Миңнегулов

Туган елы: 1939 елның 12 мае

Туган ягы: Татарстанның Зәй районы Апач авылы

Фәнни дәрәҗәсе (учёная степень): филология фәннәре докторы (1991).

Хезмәт юлы: 1962-1963 нче уку елында, КДУның читтән торып уку бүлегенә күчеп, Пенза өлкәсенең Качкару (Кутеевка) мәктәбендә мөгаллимлек кыла. 1964 елда, университетны тәмамлагач, Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылына эшкә җибәрелә, анда мәктәп директоры булып эшли. 1967 елның ноябрендә үз гаиләсе белән Казанга күчеп килә. Шуннан бирле Казан университетының татар әдәбияты тарихы кафедрасында эшли: ассистент, өлкән укытучы, доцент, профессор. Хәзерге вакытта Казан (Идел буе) федераль университетындагы Филология һәм сәнгать институтының татар әдәбияты тарихы кафедрасы профессоры.

Басылып чыккан хезмәтләре саны: 36 китап һәм җиде йөздән артык мәкалә.

Дөнья күргән кайбер китаплары: "Татарская литература и Восточная классика (Вопросы взаимосвязей и поэтики)" (1993), "Гасырлар өнен тыңлап..." (2003), "Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты" (2004), "Чит илләрдәге татар әдәбияты" (2004), "Записи разных лет (Татарская литература: история, поэтика и взаимосвязи)" (2010), "Гасырлар арасында уйланулар" (2010).

Мактаулы исемнәре: фән һәм техника өлкәсендә Татарстанның Дәүләт бүләге лауреаты; Россиянең һәм Татарстанның атказанган фән эшлеклесе; Казан университетының мактаулы профессоры; Кол Гали һәм Гаяз Исхакый исемендәге бүләкләргә, ТР Президентының Мактау грамотасына, "Казанның 1000 еллыгы" медаленә ия.

- Болгар бабаларыбыз тарафыннан ислам дине 922 елда кабул ителгән, дибез. Бу дата халкыбыз тарихында нинди роль уйный?

- Моңа дәлил итеп Ибне Фадланның Идел Болгарстанына килүе хакындагы сәяхәтнамәсе алына. Әмма бу дата олы хакыйкатьнең тик бер ягын гына чагылдыра. Ни өчен? Чөнки биредә мөселман диненең рәсми кабул ителеше турында сүз бара. Бу - бер. Икенчедән, Идел-йортка ислам дине Ибне Фадлан сәяхәтенә кадәр 2-3 гасыр элек үк керә башлый. Өченчедән, Алтын Урда чорында, ягъни XIII гасырның икенче яртысында - XIV гасырның беренче чирекләрендә оешкан татар халкы болгарлардан гына тормый. Аны шәкелләштерүдә хәзәр, кыпчак, татар һәм кайбер башка кавемнәр дә мөһим роль уйный. Аларның исә мөселман динен теге яки бу дәрәҗәдә кабул итүләре төрле чорларга карый. Дүртенчедән, безнең әби-бабаларыбызның ислам диненә керүе гомумтөрки дөнья белән дә тыгыз бәйләнешле. Чөнки төрки кавемнәр бер-берсе белән төрле багланышларда торган, еш кына үзара керешкән, бер үк дәүләт составына кергән.

- Борынгы чорда безнең җирлектә нинди диннәр хакимлек иткән?

- Борынгы төркиләрдә мәҗүси, будда, христиан, яһүди, зәрдәшт, манихей һәм кайбер башка диннәрнең теге яки бу дәрәҗәдә таралуы, тотылуы билгеле. Әмма, борынгырак чордагы мәҗүсилекне исәпкә алмаганда, аларның берсе дә ныклап тамыр жибәрә алмаган. Бу бәхет исә мөселман диненә генә насыйп була. Инде менә ул - төрки дөньяның, шул исәптән татарларның да мең елдан артык төп дине, иманы.

- Ислам диненең Идел буенда таралуы өчен нинди уңай шартлар туган була?

- Исламның безгә керүе, халыкта киң таралыш табуы сәүдә-икътисади, сәяси, мәдәни һәм башка факторлар белән бәйле. Биредә гарәп-фарсы дөньясының матди һәм рухи яктан гаять зур үсешкә ирешүе дә мөһим роль уйный. Әмма иң әһәмиятлесе һәм хәлиткече шул: ислам дине кешенең жаны, рухы, үз-үзен тотышы, әдәп-әхлагы, икенче төрле әйткәндә, җәмгыять үсешенең инсани казанышлары белән тыгыз бәйләнеше. Шуңа күрә дә ул кешеләрне, нинди кавемнән, катламнан булуына карамастан, үзенә магнит кебек тартып тора. Тагын шунысы да бар: VII-VIII гасырларда мәҗүси төркиләрдә Күк, башка илаһи көчләрдән, күренешләрдән аерып куелып, Олуг Тәңре рәвешендә карала. Бу исә нигезендә берилаһлык идеясе яткан ислам динен кабул итүгә психологик яктан уңай йогынты да ясый. Аннан борынгы гарәпләрнең һәм төркиләрнең иҗтимагый-социаль һәм рухи яшәешләрендә аерым типологик уртаклыкларның һәм охшашлыкларның да булуын онытырга ярамый.

- Төркиләрдә башлангыч чор ислам таралу ни рәвешле бара?

- Бүгенге татарларның әби-бабалары ислам дине белән төрки дөньяда һәм гарәп булмаган кавемнәр арасында иң беренчеләрдән булып кызыксына башлый. Мәгълүм ки, VII гасырның икенче чирегендә, төгәлрәк әйткәндә, 632 елда Кубрат хан житәкчелегендә Бөек Болгар дәүләте төзелә. Ул Азов диңгезе тирәләрен, Таман ярымутравын, Түбәнге Дон һәм Кубан буендагы жирләрне били. Бу мәмләкәттә үк ислам тарафдарлары булуы мәгълүм. Атаклы "Кубрат хан хәзинәсе"ндә гарәп төбәге белән бәйләнешле әйберләрнең табылуы да шул файдага сөйли. VII йөзнең урталарында Бөек Болгар дәүләте бетерелә һәм аның жирләре, төп халкы Хәзәр каганлыгы составына кертелә. Безнең әби-бабаларыбызның өч гасырдан артык яшәеш тарихын үз эченә алган Хәзәр дәүләте Евразиянең иң зур мәмләкәтләреннән берсе була. Аның төп халкын этник һәм тел ягыннан үзара якын торган хәзәрләр һәм болгарлар тәшкил итә. Хакимият, әлбәттә, аларның беренчеләре кулында була. Шуңа күрә аның составындагы башка кавемнәрне дә еш кына хәзәр дип йөрткәннәр.

- Шуннан соң Хәзәр каганлыгында дини ситуация ничек үстерелә?

- Ислам дине Хәзәр каганлыгына Бөек Болгар дәүләте яшәгән елларда, ягъни VII гасырның икенче чирегендә үк керә башлый. Мөселман Көнчыгышы белән мөнәсәбәтләрнең жанлануы бу процессны тагын да тизләтә. VIII гасырның беренче яртысында инде Идел-йортта мөселманнарның күпләп яшәве мәгълүм. Гарәпләрнең гаскәр башлыгы Мәрван жиңүләреннән соң, ягъни 737 елда (моннан 1274 ел элек) Хәзәр хакимияте ислам динен рәсми рәвештә дә кабул итә. (Кызганыч ки, бу мөһим дата моңа кадәр төрки, мөселман жәмәгатьчелеге игътибарыннан читтәрәк кала килә.) Хәзәр каганлыгында башка диннәрне тотучыларның да яшәвен онытырга ярамый. Әл-Мәсгуди язганча (943-947 нче еллар), илнең башкаласы Итилдә "мөселман, яһүд, христиан һәм мәжүсиләр бар". Патшасының "күбрәк халкы, вәзире һәм гаскәре - мөселманнар"... "Шуңа күрә Итил мәмләкәтендә өстенлек - мөселманнарда" (Мәржани Ш. Мөстәфаделәхбар фи әхвале Казан вә Болгар. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1989. - Б.120.) Шунысы мөһим: каганлыкта дини ирек саклана. Шушындый ук хәлне без бераздан Алтын Урда дәүләтендә дә күрәбез.

- Хәзәр дәүләте Болгар дәүләте үсешендә нинди урын били?

- IX гасырда Урта Иделдә Болгар мәмләкәте оеша башлый. Ул әүвәл Хәзәр дәүләтенә бәйле була. 970 елда каганлык яшәүдән туктый. Андагы хәзәрләрнең бер өлеше болгарлаша, икенче өлеше кимәк-кыпчак составына керә. Лев Гумилёв Әстерхан татарларын хәзәрләрнең турыдан-туры варисы дип тә саный.

1240 елларга кадәр яшәгән Болгар мәмләкәте һәм дәүләтчелек, һәм рухи мирас планында шактый дәрәҗәдә Хәзәр каганлыгының дәвамчысы булып тора. Анда Ибне Фадлан сәфәренә кадәр үк инде ислам диненең киң таралуы, мәчет-мәдрәсәләрнең булуы Урта гасырның күп кенә чыганакларында теркәлгән. Ил мөстәкыйльлек алгач, Урта Иделдә мөселман мәдәнияте чәчәк ата. Биредә төрле фәнни һәм әдәби китапларның язылуы мәгълүм. Мәсәлән, Тажеддин Болгариның "Әт-тирйакел-кәбир" (якынча 1219) исемле хезмәте (ул гарәп телендә) заманында Шәрык медицинасында югары бәяләнгән. (Тәһрандагы Сенат китапханәсендә сакланучы бу китап 1997 елда рус һәм гарәп телләрендә Казанда дөнья күрде.)

- Тарихыбызга кыпчаклар ничек кереп калган?

- Алар татарны барлыкка китерүдә катнашкан өченче зур компонент. Кимәк, Хәзәр һәм кайбер башка мәмләкәтләрдә, нигездә, күчмә тормыш кичерүче бу кавемнең күпчелеге мәжүси динен тота. Әмма X-XI гасырларда Шәрык сәүдәгәрләре белән аралашу, Болгар дәүләте тәэсире белән кыпчакларга да ислам дине керә башлый. Бу процесс XIII-XIV йөзләрдә киң колач ала.

- Алтын Урда дәүләтендә ислам дине зур үсеш аламы?

- Алтын Урда төзелү безнең тарихыбызның яңа сәхифәсен ачып жибәрә. Әйткәнебезчә, тел һәм этник яктан якын торган болгар, хәзәр, кыпчак, татар һәм кайбер башка кавемнәрнең кушылуыннан татар халкы формалаша, ягъни оеша, шәкелләшә. Татар кавеменең бер өлеше инде, Мәхмүд Кашгарый картасы күрсәтүенчә, XI йөзләрдә үк Көньяк Урал, Иртеш төбәкләрендә яши. Икенче өлеше исә монголлар белән бергә XIII гасырның беренче яртысында Себер якларыннан килә. Идел-йортка Көнчыгыштан килгән татарлар Бәркә (1256-1266), аеруча Үзбәк (1312-1342) хан дәверендә мөселман орбитасына керә, катлаулы этник процесста мөһим роль уйный. Шуның нәтиҗәсе буларак, Алтын Урданың төп халкы да татар исеме белән йөртелә башлый. Идел-йортның Хәзәр, Болгар чорыннан ук килә торган бай мәдәни традицияләре, Дәшт-Кыпчакның Мисыр-Сүрия белән тыгыз багланышлары Алтын Урдада да исламның төп дин булуына, мөселман рухлы мәдәниятнең, мәгарифнең зур үсеш алуына китерә. Бу хакта Ибне Батута, Ибне Гарәбшаһ кебек Урта гасыр авторлары да, Әмин әл-Холи кебек хәзерге чор галимнәре дә бертавыштан сөйли. XV йөзнең урталарында Алтын Урда яшәүдән туктый. Аның жирләрендә Кырым, Казан, Әстерхан, Нугай, Себер, Касыйм һ.б. мәмләкәтләр төзелә. Татар ханлыклары дип йөртелгән бу илләрдә ислам диненең төп дин булуы, Аллаһ Китабы Коръәни-Кәримнең киң таралуы бәхәссез. Мәсәлән, Шәрифнең "Зафәрнамәи вилаяти Казан" ядкарендә (1550) Коръән аятьләре китерелә, Казанның элек-электән "хан пайтәхете", "искедән бер мөселман шәһәре булуы" искәртелә...

- Димәк, ислам дине безнең дәүләтләребез жимерелгәч тә төп таянычыбыз, яшәү маягыбыз булган, мең елдан артык ул безнең халкыбызны рухи яктан баеткан, дип нәтиҗә ясый алабыз...

- Мең елдан артык ислам дөньясында яшәү безнең телебезгә, гореф-гадәтләребезгә, фикерләвебезгә, мәдәниятебезгә гаять зур йогынты ясаган. Нинди генә авыр вакытлар булмасын, ислам дине безнең халкыбызны саклап калды. Идел-йортта гарәп, бераздан фарсы телләрен өйрәнү Хәзәр, Болгар чорларыннан ук килә. Гарәпчә белү, ул телдә уку, язу 1917 елга кадәр зыялылык билгесе итеп каралган. Төрки-татар телендәге язмалардан тыш, безнең китапханәләрдә гарәп-фарсы телләрендәге китаплар да дөнья кадәр. Аларның бер өлеше татарның үз укымышлылары (Г.Утыз Имәни, Г.Курсави, Ш.Мәржани, М.Бигиев һ.б.) тарафыннан язылган. Телебезгә кергән күпләгән гарәп-фарсы алымнары, озак куллану нәтиҗәсендә, үз сүзләребез булып киткән. Ислам динен кабул итүгә нисбәтән, безнең әби-бабаларыбыз гарәп язуына да күчкән. Һәм бу графика татарларга мең елдан артык хезмәт күрсәткән, XX гасырның 30 нчы елларына кадәр төп алфавит булып кулланылган. Безнең язма мирасыбызның иң күп өлеше - гарәп язулы ядкарьләр. Ислам дине аеруча әдәбиятта тирән эз калдырган. Күп кенә сюжетлар, мотивлар, образлар Коръәннән алынган. Без моны Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Утыз Имәни, Тукай һ.б. бик күп әдипләрнең әсәрләрендә ачык күрәбез. Коръән, андагы идея-эстетик байлык татар язучыларын илһамландырган, иҗатларында төп юнәлешне билгеләгән, кешене, тормыш күренешләрен яктыртуда, бәяләүдә идеал, үзенә күрә бер өлгә булып хезмәт иткән.

Әңгәмәдәш – Нияз САБИРҖАНОВ

Мөхтәсибәт ЯҢАЛЫКЛАРЫ

САБА

Бүгенге көндә 170 еллык Саба Җәмигъ мәчетенә капиталь ремонт бара, - дип билгеләп үтте Саба районы имам-мөхтәсибе Айнур хәзрәт Әхмәтов. Мәчеттә ремонт булуга да карамастан, районда дини укулар өзелмәгән.

Исегезгә төшерәбез: Саба Җәмигъ мәчете I гильдияле Казан сәүдәгәре Габделкәрим Габдрәшит улы Юнысов (1859 елда үлгән) акчасына 1841 елда төзелгән. Мәчет таштан салынган. 1995 елда гыйбадәт йорты реставрацияләнә, манарасы да кайтарыла.

НУРЛАТ

- 28 октябрь көнне Түбән Нурлат авылының яңа мәчетенә манара белән ай куйдык. Биредә без Җәмигъ мәчет төзибез. Берәр айдан мәчетебезне ачарбыз, дип уйлыйм. Мәчеткә газ кертелгән, вак-төяк эчке эшләрне генә эшләп бетерәсе калды, - диде Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы имам-мөхтәсибе Айрат хәзрәт Әюпов. - 27 октябрьдә бер төркем имамнарыбыз Татарстан башкаласында урнашкан Имамнарның белемен күтәрү үзәгендә укып кайтты. Имамнарны Казанга алып барып кайту өчен автотранспорт предприятиесе директоры Кәримов Идрис Габделбәр улы ярдәм итте. Ул безгә транспорт буенча һәрдаим булышып килә. Болгарга барганда да зур ярдәм иткән иде. Октябрьнең соңгы шимбәсендә зиратларда өмә уздыкдык.

Нурлат мәдрәсәсендә шимбә-якшәмбе көнне балалар өчен укулар оештырыла. Авыл мәчет-мәдрәсәләрендә исә 29 укытучы белем бирә.

P.S.: 20 октябрьдә Кизләүдә төзелеп килүче мәчеткә дә манара куелган.

ЧҮПРӘЛЕ

"Район үзәгендәге ике һәм өч авыл мәчетендә дәресләр бара", - дип хәбәр итте Чүпрәле районы имам-мөхтәсибе Фәһим хәзрәт Әхмәтжанов.

Яңалыкларны Нияз САБИРҖАНОВ жыйды

БЕЛДЕРҮ

5 ноябрь көнне 18 сәгать 30 минутта "Раян" татар-мөселман төркеменең концерты булачак. Концерт Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә узачак. Билетлар филармония кассасында (Павлюхин ур., 73; тел.: 8 (843) 277-18-22) һәм таратучыларда сатыла. Билет бәясе 350 сумнан алып 500 сумга кадәр.

Исегезгә төшерәбез: "Раян" төркеме 2010 елда оешкан иде. Аның солистлары - озак еллар "Казан егетләре"ндә жырлаган Азат Адиев белән Вәли Фазлиәхмәтов. Әлеге музыкаль төркемнең атамасына килгәндә, ул жәннәт капкаларының берсен аңлата.



Чайнворд "Корбан бәйрәме мөбарәк булсын!"



1. Аллаһны олылау йөзеннән, "Аллаһу әкбәр!" дип кабатлау. 2. Аллаһы Тәгалә туклану өчен биргән хәләл әйберләр. 3. Шәригать кануннары буенча хөкем итүче руханый. 4. Коръән Кәримдә пәйгамбәр исеме белән аталучы сүрә. 5. Изге айда һәр көн ураза тоту гамәле. 6. Ислам дине нигезенең бер терәге. 7. Дин дәресләре укыту, өйрәтү. 8. Пәйгамбәребез (с.г.с.) туган шәһәр. 9. Мөселманнарның мөгамәләсендә, аралашуындагы традицион яхшы гадәтләр. 10. Мөселман хатын-кызлары йөзләрен, буй-сынын каплау өчен кия торган киң халат. 11. Дини изгелеге белән атаклы шәхес, гөнаһсыз изге җан. 12. Коръән Кәримнең 36нчы сүрәсе. 13. Корбан чалу турындагы уй-теләк. 14. Кылган гөнаһлы эшләр өчен үкенү, Аллаһы Тәгаләдән ярлыкау сорау. 15. Пәйгамбәр Мөхәммәд (с.г.с.) күркәм ...лы булган. 16. Исрафил фәрештә сур өргәч, үлгәннәр терелгәннән соң, аларга карата Аллаһ тарафыннан ясала торган хөкем. 17 .Корбан чалу, гыйбадәтләрне тырышып үтәү - Аллаһка ... кылу. 18. Гыйбадәттә мөселманнар йөз белән торырга тиешле як. 19. Манарадан гыйбадәт кылырга чакыру. 20. Даими гыйбадәт. 21. Корбан бәйрәме ае. 22. Корбан чалучыга Аллаһ тарафыннан языла торган савап. 23. Процент алу (хәрәм гамәл). 24. Югары дәрәҗәле дин әһеле, өлкән руханый. 25. Мөселманнарның өйләнешү йоласы. 26. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.с.) сөйләгән сүзләр. 27. Фәкыйрь-мохтаҗларга бирелә торган хәер. 28. Кояш баегач кыла торган гыйбадәт. 29. Казанның Беренче җәмигъ мәчете имамы, илаһият галиме. 30. Хаҗ кылучыларның киеме. 31. Мөселман руханыйларының башлыгы. 32. Аллаһ тарафыннан каһәрләнгән, күктән сөрелгән фәрештә, шайтаннар башлыгы. 33. Мөхәммәд (с.г.с.)нең вәгазь-күрсәтмәләре, эш-гамәле.

Җавабында: 1.Тәкбир 2.Рузык 3.Казый 4."Йосеф" 5.Фарыз 6.Зәкят 7.Тегәрмән 8.Мәккә 9. Өйләнү 10.Пәрәнҗә 11.Әйүб 12."Фәсил" 13.Нигез 14.Тәүбә 15.Әхлак 16.Кыйбләт 17.Тәкбә-лик 18.Кыйбла 19.Аян 20.Намаз 21.Зәйтүнҗәҗ 22.Әжер 23.Рибә 24.Ахун 25.Никах 26.Хәдис 27.Садака 28.Ахшам 29.Мәрҗәнә 30.Ихрам 31.Мөфти 32.Иблис 33.Сөннәт.

Изгелек җирдә ятмас...

Айдар ашыгып барган җиреннән кинәт кенә тукталып калды, кызыксынып артына борылып карады. Юл уртасында нәрсә ята соң? Үтеп-сүтеп йөрүчеләр аша шуны чамаларга тырышса да барып чыкмады.

Егет юлын тыныч кына дәвам итә алмады. Табигый кызыксынуы үзенекен итте, йөрәге дә нәрсәдер сизенгәндәй талпынып куйды. Ул шул урынга таба атлады.

Юл уртасында бер телем икмәк ята икән. Гадәти хәл инде. Бер карасаң, кулны селтисе дә, юлыңны дәвам итәсе! Ә төптәнрәк уйласаң...

Аның хәтеренә бер вакыйга килде. Кайчандыр, алар чал чәчле бабасы белән атта йөргән чыккан-нар иде. Әле дә күз алдында, кояшлы матур көн. Күк йөзе шундый көләч, әйтерсең лә үзенең зәңгәрлеге белән күзләрне иркәли, күңеленә болытларның аклыгын индерергә тырыша. Тирә-ягында иксез-чиксез иген кырлары җәелеп ята. Айдарның бабасы түзми, кулларын җәеп җибәрә:

- Күрәсеңме, улым, бу байлыкны!

Ничек күрмисең инде? Алтыннан да кыймәтрәк бит ул бөртекләр. Дөньяны алтынсу төскә күмеп җәелеп яткан шул кырларга күпме көч, тырышлык кергән. Игенченең хәләл хезмәте генә ачлыктан саклап кала безне. Шуңа күрә икмәк үстерүчеләргә дә, мәрхәмәтле Җир-Анабызга да һәрвакыт рәхмәтле булырга тиешбез.

Шулай булгач, аунап яткан бу икмәк телемен калдырып китү дөрес булырмы соң? Юк кебек. Ә нишләргә?

Айдар ярдәм эзләгәндәй як-ягына каранды. Дөнья мәшәкатенә чумган кешеләр аңа битараф караш ташлап, узып китә торды. Чарасызлыктан, егет читенсенеп кенә иелде дә, икмәк кисәген кулларына алды.

Ниндидер җылылык бар кебек шул ипи телемендә... Бик тә кадерле икән бит ул. Юк, ипинең бер валчыгын да әрәм итәргә ярамый. Тик нишләтергә соң аны?

Шулай аптырап басып торганда Айдар кемнеңдер үзенә кагылуын тойды. Борылырга да өлгермәде, ниндидер әбинең йомшак тавышы ишетелде:

- Икмәкне олылаган өчен, Ходай сине зурласын. Рәхмәт, улым!

- Нишләтим соң аны, әбекәй?

- Күгәрченнәргә ашат, улым. "Бисмилла"ны әйт тә, алларына сип. Аллаһ ризалыгы өчен булсын. Бик изге эш эшләдең.

- Ярар, әбекәй. Әйдә, бергә-бергә.

Айдар бер читтә җим эзләнеп йөрүче күгәрченнәрне күреп, шул якка китте. Бераз читенсенсә дә, бу эшне башкарырга тиешлеген аңлап, ипине учында ваклый башлады.

- Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

Җимне бирүгә кошлар сөенешеп икмәккә ябырылды. Гөр-гөр килеп валчыкларны чүпләргә кереште.

- Күрәсеңме, балам, рәхмәт әйтәләр сиңа.

Әйе... Күгәрченнәргә генә түгел, Айдарга да рәхәт иде бу минутта. Чөнки үзе дә сизмәстән саваплы эш эшләде ул. Бер яктан игенче хезмәтен олыласа, икенче яктан Аллаһы Тәгаләнең адәм балаларына бүләк иткән бәһасез нигъмәтен әрәм-шәрәм итүгә юл куймады.

Айдар кошларның җимне чүпләп бетергәнен көтеп тормады. Рәхмәт йөзеннән әбекәйгә бер кат елмайды да, үз юлына китеп барды. Карчыкның соңгы сүзләре исә егетнең күңеленә үтеп керерлек иде:

- Икмәкне хөрмәтләгез, улым! Барча кешеләр дә шундый олы йөрәкле булсыннар иде!

- Әйе шул... - диеп Айдар да ирексездән шул изге теләккә кушылды.

Алмаз МАНСУРОВ,
КФУның татар филологиясе бүлеге –
Филология һәм сәнгать институты студенты

Утыз ике йортлык авылда мәчет ачылды

29 октябрь көнне Апас районының Кече Бакырчы авылында мәчет ачылды.

Мәртәбәле вакыйгада ТР мөселманнары Диния нәзаратенең гомуми бүлек җитәкчесе, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Апас муниципаль районы башлыгы Рәшит Заһидуллин, Апас районы имам-мөхтәсибе Мирхәт хәзрәт Җамалиев, Татарстанның көньяк-көнбатыш төбәге казые Фәһим хәзрәт Әхмәтҗанов һ.б. кунаклар катнашты.

Изге эшне абыйлы-энеле Рамил һәм Радик Сибгатуллиннар башкарып чыккан. Егетләр үзләре дә, әтиләре Фәтхелислам әфәнде дә шушы Кече Бакырчы авылында туган. Гаилә әгъзалары хәзерге вакытта монда яшәмәсәләр дә, аларга туган авыллары бик тә якын: Ураза һәм Корбан гаетләренә дә авылга кайталар. Бер кайтуларында Аллаһ ризалыгы өчен җомга намазларына, дини бәйрәм-нәребезгә җыелырга уңайлы булсын өчен мәчет салу эшенә тотынган булалар. "Авырлыклар булды, әлбәттә", - ди егетләр. Ләкин халкыбызда: "Ил тотынса тау күчерер", дигән мәкаль бар бит. "Шушы мәчет төзелешендә хезмәт куйган, үзләренең киңәшләре белән булышкан кешеләрне атап, аларга олы рәхмәтемне җиткерәсем килә", - ди Рамил. Иң беренче чиратта, бу изге эштә үз фатихасын биргән район башлыгы Рәшит Нәҗип улын атый ул. Шулай ук ул ихтирам белән мәчетнең нигез ташын салудан башлап аның ачылышына кадәр булышкан Гыйсьмәтуллиннар гаиләсен (Фиргать абый, уллары Алмаз белән Ленар) искә ала.

"Фундамент салу өчен Сәлахов Мәхмүт абыйның, аның улы Айратның көче күп керде. Шулай ук мәчет күршесе Фирдүс абый белән Фирая апага да зур рәхмәтләр белдерәсе килә", - диде Сибгатуллиннар. Рәхимов Азат һәм Әмирханов Азат, Миңгәрәев Камил абый үзенең кызлары Гөлназ, Энҗе белән мәчет төзелешенә зур өлеш керткән. Төзүчеләр бригадасы - Сиражиев Рәис, Галимов Азат, Нәсыйхов Рим, Камалов Рамил, Гыймранов Илдус, Сиражиев Динар һ.б. бик тырышып эшләгән. Яшь егетләр - Ялчибаев Әлфәт һәм Мөхәммәтҗанов Азат таштан сукмак җәяргә үз теләкләрен белдергән. Авыл халкы мәчет төзүдә катнашкан эшчеләрне тәмле ризыклары белән чиратлашып сыйлады. Мәчет ачылышыннан соң бәйрәм ашы булды. Самоварлар кайнап торды, пылаулар һәм башка ризыклар белән килгән кунаклар, авыл халкы сыйланды.

Мәчет ачылышы тантанасында Коръән укылды, гыйбрәтле сүзләр сөйләнде. Ильяс хәзрәт Җиһаншин бертуган Сибгатуллиннарга Диния нәзарәтенең рәхмәт хатларын, мәчеткә бүләкләрен тапшырды. Район хакимияте башлыгы, бүтән авыл имамнары да килүдән файдаланып, кышка кергәнче зиратларда өмә үткәрик, дип мөрәҗәгать итте. Җыелган халык әлеге тәкъдимне хуплады. Җыен ахырында яңа мәчеткә "Фәтхелислам" мәчете дип исем бирелде. Мәчеткә имам итеп Фәрит хәзрәт билгеләнде.

Зөлфәт МИНГАЛИЕВ.
Автор фотосы

Казанда намаз вакытлары

Көн исеме	Дата	Иртәнге намаз	Кояш чыгу	Өйлә намазы	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
Шимбә	5.11.2011	6:26	7:56	13:02	15:38	16:56	18:26
Якшәмбе	6.11.2011	6:29	7:59	13:02	15:37	16:54	18:24
Дүшәмбе	7.11.2011	6:31	8:01	13:02	15:35	16:52	18:22
Сишәмбе	8.11.2011	6:33	8:03	13:02	15:34	16:50	18:20
Чәршәмбе	9.11.2011	6:35	8:05	13:02	15:33	16:48	18:18
Пәнҗешәмбе	10.11.2011	6:37	8:07	13:02	15:32	16:46	18:16
Җомга	11.11.2011	6:39	8:09	13:02	15:31	16:44	18:14

«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №12 (109) чыгарылыш.
Гамәлгә куючы һәм нәшир: Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
Баш мөхәррир: Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
Мөхәррир: Нияз САБИРҖАНОВ.
Дизайнер: Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
Тираж: 5000 данә. **Заказ:** Е-512.

Газета бушлай таратыла.
Редакция адресы: 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
График буенча бу санга 2 ноябрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.
Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.
Электрон адрес: niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!